КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 сентябрь г.Казань № 823

«Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 6 октябрь, 952 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 15 гыйнвар, 16 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 20 июль, 698 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 18 ноябрь, 1231 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 8 июль, 801 нче карарындагы 2 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 26 февраль, 95 нче.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 24 сентябрь, 823 нче
карары белән расланды

# «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләр булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү (алга таба шул ук эзлеклелектә – «Ел җитәкчесе» конкурсы, сайлап алуда катнашучылар, субсидия) максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирүнең максаты – Татарстан Республикасы Президентының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турында» 2002 елның 26 февралендәге ПУ-121 номерлы Указы нигезендә үткәрелә торган «Ел җитәкчесе» конкурсын оештыру һәм уздыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү.

1.3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына һәм план чорына субсидия бирүгә бюджет акчасы белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) «Ел җитәкчесе» конкурсы сайтын яңартуга һәм аның эшләвен тәмин итүгә чыгымнар;

узган ел үткәрелгән «Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары турында истәлекле китап чыгаруга чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатларын бүләкләү тантанасын әзерләүгә

чыгымнар (бүләкләү тантанасына чакыру билетларын эшләү һәм бастырып чыгару, бүләкләү тантанасы өчен утырту схемаларын типографиядә әзерләү, бүләкләү тантанасы өчен видеороликлар, залны бизәү өчен чәчәк бәйләмнәре һәм чәчәк композицияләре, залны арендалау, бүләкләү тантанасы өчен тавыш һәм ут техникасы, бәйрәм ашы (хезмәт күрсәтеп));

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турында нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 29 мартындагы 161 номерлы карары белән каралган «Ел җитәкчесе» конкурсында катнашучылар (номинантлар) җитәкләгән предприятиеләрне һәм оешмаларны кертеп, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының предприятиеләр һәм оешмалар (икътисадый эшчәнлек төрләре буенча) рейтингын билгеләү хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатларының бүләкләү атрибутикасын әзерләүгә чыгымнар (билге, таныклык, футляр, диплом бланкы һәм багетлы рама);

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәсе бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле (автомобильне карап тотуны, техник карау уздыруны, аңа хезмәт күрсәтүне һәм ягулык-майлау материалларына чыгымнарны үз эченә алган) транспорт чыгымнары;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле элемтә һәм «Интернет» челтәре хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле финанс оешмалары хезмәтләренә чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле оештыру техникасы өчен канцелярия һәм чыгым материаллары сатып алуга чыгымнар;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга җәлеп ителә торган субсидия алучы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыру һәм уздыру өчен граждан-хокукый шартнамәләре нигезендә җәлеп ителә торган белгечләрнең хезмәтләре өчен түләүгә, шулай ук узган елда уздырылган «Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары турында истәлекле китап бастыру өчен материаллар әзерләүгә чыгымнар.

1.5. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n + Z_1 + Z_2 + Z_3,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми

сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар («Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга җәлеп ителә торган субсидия алучы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр чыгымнары, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының предприятиеләр һәм оешмалар (икътисадый эшчәнлек төрләре буенча) рейтингын билгеләү хезмәтләре өчен түләү чыгымнарыннан тыш) суммасы ;

$Z_1$ – «Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга җәлеп ителә торган субсидия алучы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнары, алар «Ел җитәкчесе» конкурсын оештыру һәм уздыру кысаларында чараларны гамәлгә ашыру план-графигы нигезендә кирәкле эш вакытын, штат расписаниесе буенча вазыйфаи окладларны, субсидия алучының локаль норматив актларында каралган стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алып билгеләнә;

$Z_2$ – Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәсе бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә чыгымнар;

$Z_3$ – «Ел җитәкчесе» конкурсында катнашучылар (номинантлар) җитәкләгән предприятиеләрне һәм оешмаларны кертеп, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының предприятиеләр һәм оешмалар (икътисадый эшчәнлек төрләре буенча) рейтингын билгеләү хезмәтләренә түләү өчен Дәүләт статистикасы федераль хезмәте җитәкчесе тарафыннан расланган мәгълүмати хезмәтләр күрсәтү турында 2018 елның 29 октябрендәге 153-у номерлы шартнамә нигезендә Статистика мәгълүматы бирү кыйммәтен исәпләү тәртибе нигезендә билгеләнә торган чыгымнар;

1.6. Субсидия бирү нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге субсидия бирү нәтиҗәләре кулланыла:

«Ел җитәкчесе» конкурсы номинацияләре саны – кимендә 6;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, иҗтимагый һәм башка оешмаларның «Ел җитәкчесе» конкурсында катнашучылар буенча тәкъдимнәр әзерләүгә җәлеп ителүчеләр саны – кимендә 10;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының «Ел җитәкчесе» конкурсында катнашучылар турында тәкъдимнәр әзерләүгә җәлеп ителүчеләр өлеше – кимендә 90 процент;

«Ел җитәкчесе" конкурсы номинантлары булган җитәкчеләр саны – кимендә 60;

«Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары саны – кимендә 12;

бүләкләү атрибутикасының тапшырылган комплектлары саны – кимендә 12;

узган ел үткәрелгән «Ел җитәкчесе» конкурсы лауреатлары турында басылып чыга торган китап нөсхәләре саны – кимендә 200.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

1.7. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.8. Субсидияләр алучыны сайлап алуны (алга таба – сайлап алу) үткәрү алымы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу – сайлап алуны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып уздыру.

1.9. Субсидия алучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

заявка бирү датасына уңай имидж формалаштыруга, илебезнең иң яхшы менеджерлары – предприятиеләр (оешмалар) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр, эшкуарлар тәҗрибәсен җәмәгатьчелек тарафыннан тануга һәм аларның тәҗрибәсен таратуга ярдәм итүче чараларны оештыру һәм уздыру тәҗрибәсенә ия.

## II. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

2.1. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына карата сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын

тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәй салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары юк йә бурыч Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

2.2. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба - «Электрон бюджет» системасы) сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

## III. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Сайлап алу Министрлык тарафыннан «Электрон бюджет» системасында гамәлгә ашырыла. Министрлыкның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

3.2. «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

3.3. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлык тарафыннан, «Электрон бюджет» системасында Министрлык белдерүне формалаштырган көннән алып биш эш көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланып, бердәм порталда субсидия турында мәгълүмат басылып чыкканнан соң урнаштырыла.

3.4. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта заявкаларны кабул итеп алу тәмамлану датасы  сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән бишенче календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 1.6 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән датага туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

әлеге Тәртипнең 1.9 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 5.1 – 5.6 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

әлеге Тәртипнең 5.7 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 6.1 – 6.4 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү

кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 6.5 пункты нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга әлеге Тәртипнең 5.8 – 5.9 пунктлары нигезендә сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатманы бирә башлау датасы һәм биреп бетерү срогы;

сайлап алуда җиңүче әлеге Тәртипнең 7.1 пункты нигезендә килешүгә кул куярга тиешле срок;

сайлап алуның җиңүчесен әлеге Тәртипнең 7.4 пункты нигезендә килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mert.tatarstan.ru/) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

4.1. Министрлык тарафыннан бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкаларны бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

4.2. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

4.3. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат бирә.

4.4. Сайлап алу бердәм порталда аны уздырмау турында белдерү урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

4.5. Әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) белән килешү төзелгәнче Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка

килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

## V. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар булдыру һәм бирү тәртибе

5.1. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявкаларны «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштыра һәм тапшыра, түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) «Электрон бюджет» системасына күчереп кертә:

гамәлгә кую документлары;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыру һәм уздыру кысаларында чараларны гамәлгә ашыруның план-графигы, кирәкле эш вакытын исәпләп;

штат расписаниесе;

сайлап алуда катнашучының сайлап алуда катнашучы хезмәткәрләргә кызыксындыру түләүләрен күздә тотучы локаль норматив хокукый актлары;

уңай имидж формалаштыруга, җәмәгатьчелектә танылуга һәм үзебезнең иң яхшы менеджерлар – предприятие (оешма) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр, эшмәкәрләр тәҗрибәсен таратуга ярдәм итүче чараларны үткәрүдә катнашучы тәҗрибәсе турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе тарафыннан имзаланган белешмә;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән беркетелгән сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптәге 6 пунктта билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында белешмә кәгазе (ирекле формада);

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

«Ел җитәкчесе» конкурсын оештыруга һәм уздыруга субсидияләр акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылырга планлаштырыла торган чыгымнар сметасын сайлап алуда катнашучы җитәкче тарафыннан расланган, аның күләмен нигезләүче мәгълүмат күрсәтелеп, чыгымнарның планлаштырыла торган юнәлешләренең калькуляциясен финанс-икътисадый нигезләү кушымтасы белән (товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең счетлары, коммерция тәкъдимнәре, җитештерүче оешмаларның бәяләре, дәүләт статистикасы органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп).

5.2. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

сайлап алуда катнашучыны дәүләт теркәвенә алу датасы;

юридик затның адресы;

элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда));

б) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

в) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәләре, соратып алына торган субсидия күләме.

5.3. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

5.4. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

5.5. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә сакланган булырга тиеш түгел.

Заявкага кертелгән фото- һәм видеоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

5.6. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү датасы булып, заявкага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

5.7. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.1 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.8. Теләсә кайсы сайлап алуда катнашучы бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән, заявкалар тапшыру тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында их күбе ике рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

5.9. Министрлык әлеге Тәртипнең 5.8 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү

тәмамланганга кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VI. Заявкаларны карау тәртибе, шулай ук сайлап алуда җиңүчене билгеләү

6.1. Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкаларны карау өчен аларга Министрлык керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Министрлыкка «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелгән заявкаларга керү мөмкинлеге бирелә.

6.2. Министрлык сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән өч эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

юридик затның адресы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

6.3. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

6.4. Әгәр заявка сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әгәр заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаса, ул дөрес дип таныла.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

6.5. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кире кагу өчен нигезләр:

сайлауда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның һәм (яисә) заявкаларның сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

6.6. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуның һәр катнашучысы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

6.7. Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

6.8. Кергән заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

6.9. Сайлап алуда җиңүче булып сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә кергән заявкаларны ранжировкалау нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан төзелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучы таныла.

6.10. Сайлап алуны төгәлләү һәм анда җиңүчене ачыклау максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчесен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм "Электрон бюджет" системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куйган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла, һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган

субсидиянең күләме.

6.11. Сайлап алу түбәндәге очракларда уздырылмаган дип танылa:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

VII. Килешү төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

7.1. Министрлык тарафыннан сайлап алу нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт.

Килешү үз эченә субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.

Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

7.2. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый

калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

7.3. Сайлап алуда җиңүче килешүне төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән срокта килешүгә имза куймаган очракта, Министрлык заявка рейтингы кимү тәртибендә заявкасы бирелгән сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи.

7.4. Сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

7.5. Министрлык килешүләр төзүне төгәлләү срогын сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия алучыга субсидия бирү турында карар кабул итә, ул Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

7.6. Министрлык субсидия алучыга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетына күчерә.

## VIII. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру хисабын бирү тәртибе

8.1. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасы аша килешүләр өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формада каралган форма буенча хисаплар бирә:

субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап:

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап.

8.2. Министрлык әлеге Тәртипнең 8.1 пунктында каралган субсидия алучы тарафыннан тапшырылган хисапларны «Электрон бюджет» системасында аларны алу датасыннан 20 эш көне эчендә тикшерә.

8.3. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешү-не һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

8.4. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.

Министрлык әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган хәлләр ачыкланган көннән 30 календарь көннән артмаган срокта субсидия алучыга таләп алынган көннән 10 календарь көн эчендә субсидияне кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.

8.5. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартыннан дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

8.6. Субсидия алучының субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына ирекле кайтарудан баш тарткан яисә читләшкән очракта, Министрлык аларны мәҗбүри түләтү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар кабул итә.

Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 8.4 һәм 8.4 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

8.7. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.